ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ҮЗИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

№ 10

2020 елның 10 ноябре

«Аксубай муниципаль районы Иске Узи авыл җирлегенең Яңа Мукшы авылы гражданнарның үзара салымын кертү һәм акчаларын куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Иске Үзи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы 24 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. ТР, Аксубай районы, Яңа Мукшы авылы, Ленин урамы, 20 нче йорт адресы буенча урнашкан Яңа Мукшы күпфункцияле үзәге бинасында 2020 елның 20 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Мокшино авыл җирлегенең Яңа Мукшы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
   «2021 елда үзара салым акчаларын түләүләргә Аксубай муниципаль районының Иске Үзи авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 500 сум күләмендә акча кертүгә, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә урамнарны кышкы карап тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу);

- юл полотносы урнаштыру, (грунт күтәрү, авыл урамнарын ком һәм вак таш белән җәю)

- вак таш сатып алу;

2. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу;

- җәяүлеләр кичү юлын ремонтлау (күпер), (товарлар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, шулай ук ТР Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында халыкка хәбәр итәргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Аксубай муниципаль районы
Иске Үзи авыл җирлеге башлыгы: Н.В.Айдова